**РАСЛЫЙМ**

**Мәгариф идарәсе начальнигы**

___________Р.Т.Демидов

**Якташ язучы Фоат Садриевның иҗади мирасын өйрәнү, пропогандалау максатыннан мәктәп укучылары һәм укытучылар арасында IV республикакүләм "Фоат Садриев укулары – 2017" нигезләмәсе**

**Республикакүләм Фоат Садриев укулары Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, якташ язучыбыз, Мөслим төбәге әдипләре, күренекле фән эшлеклеләре, сәнгать әһелләре, башка өлкәләрдә танылган шәхесләрнең иҗатын өйрәнү, пропагандалау, 2014-2020 нче елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасын тормышка ашыру һәм укучыларда тикшерү, коммуникатив хәбәрдарлык формалаштыру, фәнни эзләнүләрдә иҗадилыкка омтылыш тәрбияләү максатыннан үтәрелә.**

1. **Укуларның максаты:**

- Укытучыларны, укучыларны фәнни-эзләнү эшләренә тарту;
- матур әдәбият аша туган телгә, милләткә карата хөрмәт тәрбияләү;
- сәләтле балаларны ачыклау һәм аларның үсеше өчен шартлар тудыру;
- гомуми төп, урта белем бирү йортларында белем бирүче укытучыларны үстерү юлларын билгеләү, тәҗрибә уртаклашу.

2. **Бурычлары:**

- Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, күренекле язучы Фоат Садриев, Мөслим төбәге әдипләре, күренекле фән эшлеклеләре, сәнгать әһелләре, башка өлкәләрдә танылган шәхесләрнең иҗатын өйрәнү;
- Укытучыларда, укучыларда фәнни-тикшеренү күнекмәләрен камилләштерү.

**3. Катнашучылар**:

Республикакүләм Фоат Садриев укулары гомуми белем бирү оешмаларының, гимназия, лицейларның татар теле һәм әдәбияты укытучылары, 2-11 нче сыйныф укучылары катнаша.

4. **Үткәрү шартлары һәм тәртибе**

Бәйге 2 турда үткәрелә:

- I тур - 2017 нчы елның 3 нче мартына кадәр Мөслим муниципаль районының мәгариф идарәсе бәйгедә катнашу өчен гаризалар, фәнни эшләр, тезислар кабул итә. Гариза, тезис һәм фәнни эшне nurania.shai@tatar.ru адресына җибәрергә кирәк. (хәбәрләшү өчен телефон 8(85556) 2-40-49, 89274804700, 89196332598 Нурания Әзһәмовна). 6 нчы марттан 15 нче мартка кадәр эшләр комиссия тарафыннан тикшерелә һәм иң яхшы эшләргә чакыру җибәрелә.

II тур - 29 нчы март көнне Мөслим гимназиясендә үткәрелә. (Адрес: Мөслим авылы, Кооператив урамы, 170 нче йорт).

Укытучы яки укучы үзе сайлаган темага чыгыш әзерли (эзләнү эше, мастер-класс, проект эше)

ЭЗЛӘНҮ ЭШЛӘРЕ ӨЧЕН ТҮБӘНДӘГЕ ЮНӘЛЕШЛӘР ТӘКЪДИМ ИТЕЛӘ:

**1 нче юнәлеш: "Фоат Садриев иҗаты: заман һәм шәхес"** (Фоат Садриев иҗаты буенча укучыларның, укытучыларның, балалар бакчалары тәрбиячеләренең, китапханәчеләрнең фәнни-эзләнү эшләре)

**2 нче юнәлеш: "Сүз чыгар шагыйрьләрдән хикмәт белән"** (Мөслим төбәге әдипләре иҗаты буенча укучыларның, укытучыларның, балалар бакчалары тәрбиячеләренең, китапханәчеләрнең фәнни-эзләнү эшләре)

Шагыйрьләр Харрас Әюп (Харрас Гыйльмегали улы Әюпов) һәм Зөлфәт (Дөлфәт Госман улы Маликов), Фәрит Гыйльми, Эльмира Шәрифуллина, Наис Гамбәр 70 еллыгына багышлана.

**3 нче юнәлеш: Мөслим төбәгенең күренекле сәнгать әһелләре**

Г.Камал театрының күренекле актеры Наил Әюпов һәм Кәрим Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма һәм комедия театры артисты Зөфәр Харисовның юбилейларына, күренекле татар актеры, җырчы, Татарстанның атказанган артисткасы Зифа Басыйрова иҗатына, районыбыздан чыккан башка күренекле сәнгать

эшлеклеләренә багышлана (презентацияләр бәйгесе. Слайдлар 10 нан артмавы шарт. Бер укытучы бер генә эшнең җитәкчесе була ала. Бәйге 2-6 нчы сыйныф укучылары өчен).

**4 нче юнәлеш: Мөслим төбәге тарихын һәм язучылары, шагыйрьләре иҗатын мәктәптә өйрәнү.**
**(**укытучыларның фәнни-эзләнү эшләре, Мөслим төбәге тарихын, язучылар иҗатын өйрәнү юнәлешендәге иҗади проектлар, презентацияләр, авторлык электив курс программалары, мастер-класслар)

**5. Хезмәтнең язылу тәртибе**

Эшләр татар телендә, текстның күләме 8 басма биттән артмаска тиеш. Эзләнү эшендә материаллар рәсем, схема һәм карта, фотосурәтләр булырга мөмкин, күләме 5 бит). Эш төзәтүләрсез, А4 форматында (шрифт Times New Roman – 14. Полялар: сулдан - 30 мм, уңнан-15мм, астан һәм өстән-20 мм. Юл аралырында 1,5 интервал кала. Кызыл юл 1 см калдырылып башлана) компьютерда басылган булырга тиеш. Эзләнү эшләре папкага тегелеп тапшырыла.

Титул битенә белем бирү оешмасының тулы исем (устав буенча), район, укучының яки укытучының фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, тема языла.

**6. Бәяләү критерийлары**

- проблеманы чишүнең тирәнлеге, тулылыгы, үзенчәлекле ысуллары кулланылган булуы;
- логик яктан дөрес фикерләү, ышандырырлык, дәлилләнгән нәтиҗәләр ясау;
- эшнең фәннилеге;
- эшнең максатын дөрес билгеләү;
- авторның мөстәкыйльлек дәрәҗәсе;
- чыгышның композицион бөтенлеге, дәлилли белү, теманы ача белү дәрәҗәсе;
- чыгышны күрсәтмә материаллар белән баету;
- заман таләпләренә туры килүе;
- чыгыш ясаучының сөйләм, аралашу культурасы.

Чыгыш ясау өчен 5-7 минут вакыт бирелә. Шул вакыт эчендә укучы төп фикерләрне кыска һәм төгәл итеп җиткерә белергә тиеш.

**Игътибар! Тәкъдим ителә торган мәкаләләр, аудио, видео, фоторзсемнәр, тиешле таләпләр сакланган очракта, укуларны үткәрү көненә кадәр www.magarif-uku.ru сайтында, ә иң яхшы берничәсе "Мәгариф" журналында чыгачак. Фоторәсемнәрне Word файлы эченә, ягъни текст арасына салырга ярамый, фәкать JPEG форматында гына тәкъдим итәргә кирәк.**

**Аерым Word документында (2 нче документта) түбәндәге үрнәктәге гариза тутырыла һәм аның астына 16027 индексы буенча "Мәгариф", "Гаилә һәм мәктәп" журналларына 2017 нче елның икенче яртыеллыгына язылу турында квитанция күчермәсе беркетелә.**

**7. Конференцияне йомгаклау һәм нәтиҗә ясау:**

Республикакүләм Фоат Садриев укуларында катнашучыларның чыгышы алдан билгеләнгән критерийлар буенча бәяләнә.

Катнашучыларның чыгышларын тыңлап бетергәннән соң, эксперт комиссиясе утырышы үткәрелә һәм җиңүчеләр турында карар чыгарыла.

Эксперт комиссиясенең карары турында беркетә языла.

Республикакүләм Фоат Садриев укуларында катнашучыларга сертификатлар, җиңүчеләргә мәгариф идарәсенең дипломнары, нәтиҗәле чыгыш ясаучыларга рәхмәт хатлары тапшырыла.

**III республикакүләм "Фоат Садриев укулары – 2017" оештыру комитетына гариза**

| Белем бирү учреждениесе (устав буенча) | Катнашучы укучының, укытучының фамилиясе, исеме, атасының исеме, укыган сыйныфы | Чыгышының исеме | Фәнни җитәкченең ФИО | Телефон, электрон почта, адрес |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |